ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ ГОРОДА ИННОПОЛИС

ул. Спортивная, д.114, г.Иннополис,
Верхнеуслонский район,
Республика Татарстан, 420500

ИННОПОЛИС ШӘҺӘРЕНЕҢ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

Спортивная ур., 114-нче йорт, Иннополис
шәһәре, Югары Ослан районы, Татарстан
Республикасы, 420500

тел. (843) 212-27-24, e-mail: city@innopolis.ru, www.verhniy-uslon.tatarstan.ru/rus/innopolis.htm

ПОСТАНОВЛЕНИЕ | КАРАР

г. Иннополис | №

01.02.2021 | №2

Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районының «Иннополис шәһәре» муниципаль берәмлегендә җирләү буенча хезмәтләрнең гарантияле исемлеге нигезендә күрсәтелә торган хезмәтләрнең хакын раслау турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003нче елның 6нчы октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, «Күмү һәм күмү эше турында» 1996 елның 12нче гыйнварындагы 8-ФЗ номерлы Федераль закон, «2021нче елда түләүләр, пособиеләр һәм компенсацияләр индексациясе коэффициентын раслау турында» Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2021нче елның 28 гыйнварындагы 73нче номерлы карары, «Татарстан Республикасында җирләү һәм күмү эше турында» Федераль законны гамәлгә ашыру чаралары турында» 2007нче елның 18нче маендагы 196нчы номерлы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карары нигезендә, Иннополис шәһәре Башкарма комитеты

КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районының «Иннополис шәһәре» муниципаль берәмлегендә 2021нче елның 1нче февраленнән башлап, 1нче кушымта һәм 2нче кушымта нигезендә, җирләү буенча хезмәтләрнең гарантияле исемлеге буенча 6424,98 сум күләмендә хезмәт күрсәтү бәясен билгеләргә һәм гамәлгә кертергә.

2. «Күмү буенча хезмәтләр күрсәтүнең гарантияләнгән исемлеге нигезендә күрсәтелә торган хезмәтләр бәясен раслау турында» 2020нче елның 31нче гыйнварындагы 4нче номерлы Иннополис шәһәре Башкарма комитеты карары үз көчен югалткан дип танырга.

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (http://pravo.tatarstan.ru), Югары Ослан муниципаль районының рәсми

сайтында Интернет - телекоммуникация челтәрендә (http://verhniy-uslon.tatarstan.ru), Иннополис шәһәре мэриясе бинасында урнашкан махсус мәгълүмат стендында бастырып чыгарырга.

4. Әлеге карарның үтәлешен үзем контрольдә тотам.

Җитәкче Р. Р. Шагалиев

Иннополис шәһәре Башкарма комитетының
2021нче елның 1нче февраленнән
02нче карарына

1нче кушымта

Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районының «Иннополис шәһәре» муниципаль берәмлегендә 2021нче елның 1нче февраленнән күмү буенча хезмәтләр күрсәтүнең гарантияләнгән исемлеге бәясе

| № | Хезмәт күрсәтү атамасы | Хезмәт күрсәтү бәясе-1 сум.) |
|---|---|---|
| 1. | Җирләү өчен кирәкле документларны рәсмиләштерү | 0 |
| 2. | Җирләү өчен кирәкле табут һәм башка предметларны бирү һәм китерү | 3 501,30 |
| 3. | Мәрхүмнең җәсәден (җәсәдләрен) зиратта ташу | 997,40 |
| 4. | Җирләү (каберләрне казу һәм күмү) | 1 926,28 |
| Барлыгы | | 6 424,98 |

Иннополис шәһәре Башкарма
комитеты 2021нче елның 1нче
февраленнән 02нче карарына
2нче кушымта

Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районының «Иннополис шәһәре» муниципаль берәмлегендә җирләү буенча хезмәтләрнең гарантияле исемлеге

| № | Хезмәт күрсәтү атамасы | Хезмәт күрсәтү бәясе-1 сум.) |
|---|---|---|
| 1. | Җирләү өчен кирәкле документларны рәсмиләштерү | 0 |
| 2. | 2. Мәетне кәфенләү | 618,58 |
| 3. | Җирләү өчен кирәкле табут һәм башка предметларны бирү һәм китерү | 2 882,72 |
| 4. | Мәрхүмнең җәсәден (җәсәдләрен) зиратта ташу | 997,40 |
| 5. | Җирләү (каберләрне казу һәм күмү) | 1 926,28 |
| Барлыгы | | 6 424,98 |